| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.08.2023 ел Баулы шәһәре 106

“Баулы шәһәр Советының
депутат статусы турында
Нигезләмәне раслау турында”
2023 елның 6 мартындагы
88 номерлы Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Баулы шәһәр Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 06.03.2023 елның 6 мартындагы 88 номеры карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 статьясының 1 өлешендәге 12 пунктта "барлык" сүзен төшереп калдырырга;

17 статьясының 1 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срокка, ел саен,үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, гамәлдәге законнар нигезендә ел саен, вакытында белешмәләр тапшырырга (Баулы шәһәр Советы депутатлары муниципаль депутат вазифаларын биләүче затлардан һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручылардан тыш).»;

18 статьяның 1 өлеше 2 пунктындагы а) һәм б) пунктчаларында “муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына” дигән сүзләрен төшереп калдырырга;

19 статьяның 1 өлешендә “кырыс” сүзен төшереп калдырырга;

20 статьяның 3 өлешендә “федераль закон” сүзләрен “федераль закон чыгару” сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru.адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр эшләре мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров